| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2018 Баулы шәһәре № 186

2019 елда Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
мәктәпләрендә бушлай туклану
белән тәэмин итү турында

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты үтенечен карап, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елда шәһәр һәм районның гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы дүрт һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдәге балаларны бушлай тукландыру белән тәэмин итәргә.

2. Финанс-бюджет палатасына 2019 елда район бюджеты үтәлеше барышында күп балалы гаиләләргә (дүрт һәм аннан да күбрәк бала) льготалар бирү чыгымнарын каплауга финанс мөмкинлек табарга.

3. "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә район һәм шәһәр мәктәпләрендә укучы дүрт һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләргә әлеге карарда күздә тотылган социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүматны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендә кабул ителгән 181 санлы карары һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә (урнаштыруны) тәэмин итәргә.

Социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССО операторы тарафыннан

билгеләнгән форматларга туры китереп, ЕГИССО куллану юлы белән алынырга мөмкин.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Баулы муниципаль районы Советының Бюджет һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин